вә а́лә' ә'ли Ибра'һи'мә иннәкә Хәми'ду-Ммәҗи'д"

*"Ий, Раббым, Ибраһим галәйһиссәләмгә һәм аның әһеленә рәхмәт кылганың кебек, Мөхәммәд галәйһиссәләмгә һәм аның әһеленә дә рәхмәт кыл! Тәхкыйк, Син Мактаулы һәм Олугсың. Ий, Раббым, Ибраһим галәйһиссәләмгә һәм аның әһленә бәрәкәт биргәнең кебек, Мөхәммәд галәйһиссәләмгә һәм аның әһеленә дә бәрәкәт бир! Тәхкыйк, Син Мактаулы һәм Олугсың".*

Аннан соң Алла'һы Тәгаләдән дүрт нәрсәдән саклану сора:

"اَللَّهُمَّ إِنِّي أَعُوذُ بِكَ مِنْ عَذَابِ الْقَبْرِ، وَمِنْ عَذَابِ جَهَـنَّمَ، وَمِنْ فِتْنَةِ الْمَحْيَى وَالْمَمَاتِ، وَمِنْ شَرِّ فِتْنَةِ الْمَسِيحِ الدَّجَالِ"

**"Алла'һуммә инни' әү'зу бикә мин а́зә'биль-кабр, вә мин а́зә'би җәһәннәм, вә мин фитнәтиль-мәхьә' вәль-мәмә'т, вә мин шәрри фитнәтиль-мәси'хи-ддәҗҗә'л"**

*"Ий Раббым, мин Сиңа кабер газабыннан, ут газабыннан, дөнья һәм үлем фетнәләреннән һәм яман Дәҗҗәл фетнәсеннән сыгынамын".*

Сәлам биргәнче, Алла'һыдан теләгәненңне сорасаң була, мисал өчен:

"اَللَّهُمَّ أَعِنِّي عَلَى ذِكْرِكَ وَشُكْرِكَ وَحُسْنِ عِبَادَتِك"

**"Алла'һуммә әынни' а́лә' зикрикә вә шукрикә вә хусни ыйбә'дәтик"**

*"Ий, Раббым Алла'һ, миңа Сине зекер итәргә, Сиңа шөкер итәргә һәм Сиңа яхшы итеп гыйбадәт кылырга ярдәм бир"*

"اَللَّهُمَّ إِنِّي أَسْأَلُكَ الْجَنَّةَ وَأَعُوذُ بِكَ مِنَ النَّارِ"

**"Алла'һуммә инни' әс-әлукәль-җәннәтә вә әү'зу бикә минә-ннә'р"**

*"Ий, Раббым Алла'һ, мин Синнән җәннәт сорыйм һәм җәһәннәм утыннан сыгынамын".*

(12) Башта уң ягыңа, аннары сул ягыңа сәлам бир:

"اَلسَّلَامُ عَلَيْكُمْ وَرَحْمَةُ اللهِ"

**"Әссәлә'му а́ләйкүм вә рахмәту-Лла'һ"**



*"Сезгә Алла'һның сәламе һәм рәхмәте булсын".*

(13) Әгәрдә намаз ахшам намазы кебек өч рәкәгатьле булса, яки өйлә һәм икенде һәм ястү намазлары кебек дүрт рәкәгатьле булса, тәшәһһүд догасын укы. Аннан соң тезләреңә кулың белән таянып, өченче рәкәгатькә тор (киресенчә 3-нче сүрәт), әйтеп:

"اَللَّهُ أَكْبَرُ" **"Алла'һу әкбәр"**

(14) Фатиха сүрәсен генә укып, намазыңны алда күрсәтелгәнчә дәвам ит. Ахшам намазының өченче рәкәгатеннән соң, өйлә, икенде һәм ястү намазларының дүртенче рәкәгатеннәң соң утырып тәшәһһүд догасын укы. Аннары Салават догасын укып һәм догалар кылып сәлам бир. (7-нче сүрәт).


7

**Намазыңны өйрәтелгән тәртип буенча, җиренә җиткереп укы, ашыгып укыма.**

(15) Ир-ат кеше фарыз намазларын җәмәгать белән мәчеттә укырга тиеш.Ялкауланырга тиеш түгел. Шулай эшләсә, инша Алла'һ, Кыямәт көнендә уңышка ирешүчеләрдән булыр.

(16) Һәрбер мөселман ир-атка һәм мөселман хатын-кызга, сәфәрдә булмаганда, көн саен уникe рәкәгать нәфел намазы уку мөстәһәб санала. Алар: Иртәнге намаз алдыннан 2 рәкәгать, өйлә алдыннан 4 рәкәгать, өйләдән соң 2 рәкәгать, ахшамнан соң 2 рәкәгать һәм ястүдән соң 2 рәкәгать. Пәйгамбәребез ﷺ әйтә: *"Кем көнендә һәм кичендә 12 рәкәгать нәфел намазлары укый, аңа шул сәбәпле җәннәттә йорт төзелер"* (Хәдисне Муслим риваять итә 728-нче хадис). Сәфәрдә иртәнге намазының сөннәте укыла, башка сөннәт намазлар укылмый.



**(17) Намаз укучыларның кайбер хаталары:**

1-җәмәгать намазында, имамнан узып уку

2-намаз вакытында, өскә карау

3-имамнан алда сәлам бирү




## ҖЕНАЗА НАМАЗЫНЫҢ ТӘРТИБЕ

(1) "Мәеткә җеназа намазы укырга", - дип күңелең белән ниятлә дә, кулларны күтәреп тәкбир-ихрам әйт (1-нче сүрәт):

"اَللَّهُ أَكْبَرُ" **"Алла'һу әкбәр"**

уң кулыңны сул кулың өстене куеп Фатиха сүрәсен укы.



(2) Икенче тәкбирне әйт:

"اَللَّهُ أَكْبَرُ"

**"Алла'һу әкбәр"**

һәм салават догасын Пәйгамбәребезгә ﷺ укы.



(3) Өченче тәкбирне әйт:

"اَللَّهُ أَكْبَرُ" **"Алла'һу әкбәр"**

һәм мәеткә ошбу доганы кыл:

"اَللَّهُمَّ اغْفِرْ لِحَيِّنَا وَمَيِّتِنَا وَشَاهِدِنَا وَغَائِبِنَا وَصَغِيرِنَا وَكَبِيرِنَـــا وَذَكَرِنَا وَأُنْثَانَا. اللَّهُمَّ مَنْ أَحْيَيْتَهُ مِنَّا فَأَحْيِهِ عَلَى الْإِسْلَامِ وَمَنْ تَوَفَّيْتَهُ مِنَّا فَتَوَفَّهُ عَلَى الْإِيمَانِ"

**"Алла'һуммә-гъфир ли хәййинә' вә мәййитинә' вә шә'һидинә' вә га'ибинә' вә сагыйринә' вә кәби'ринә' вә зәкәринә' вә унсә'нә'. Алла'һуммә мән ахьяйтәһу миннә' фәахьиһи а́ләль-ислә'м вә мән тәваффәйтәһү миннә' фә тәваффәһү а́ләль-и'мә'н"**

*"Ий, Раббым, безнең терекләребезне дә, үлекләребезне дә, монда булганнарыбызны да, булмаганнарыбызны да, кечкенәләребезне дә, олыларыбызны да, ирләребезне дә, хатыннарыбызны да ярлыка. Ий, Раббым, терек булганнарыбызны Ислам дине үзәренә терек кыл, үләннәребезне иман белән вафат кыл".*

(4) Дүртенче тәкбирне әйт:

"اَللَّهُ أَكْبَرُ" **"Алла'һу әкбәр"**

һәм сәлам әйт: "اَلسَّلَامُ عَلَيْكُمْ وَرَحْمَةُ اللهِ"

**"Әссәлә'му а́ләйкүм вә рахмәту-Лла'һ"**

**Пәгамбәребез, Аллаһының аңа салават-сәламнары булса иде, җеназа турында шулай диде:** *"Кем мәет озатуын күреп, җ наза намазында катнашса, аңа бер кыйрат кадәрле әҗер-савап булыр, ә кем мәетне күмгәнчегә хәтле калса, аңа ике кыйрат кадәрле әҗер-савап булыр".* Пәйгамбәребездән сорадылар: "Ни кадәр соң ул ике кыйрат?" Ул аларга: *"Ике бөек тау хәтле"*, - дип җавап кайтарды. (әл-Бохари 1325-нче хәдис, Мөслим 945-нче хәдис)

**Икенче бер хәдисендә Аллаһның илчесе мондый сүзләр әйтте:** *"Җеназаны ашыктырыгыз! Әгәр дә (мәетегез) яхшы булса – яхшылыкка илтерсез. Әгәр начар булган икән – җилкәгездән төшерерсез".* (әл-Бохари 1315-нче хәдис, Мөслим 944-нче хәдис)

رقم سجل لدى الادارة العامة للبحوث، والتأليف، والترجمة بالأزهر الشريف (17898)



بسم الله الرحمن الرحيم

25

Алла'һы Тәгалә әйтә:

﴿إِنَّ الصَّلَاةَ كَانَتْ عَلَى الْمُؤْمِنِينَ كِتَابًا مَوْقُوتًا﴾ النساء– 103

**"Дөреслектә, намаз, мөэминнәр өчен билгеләнгән вакытларда, фарыз гамәл булып йөкләтелде"**

Пәйгамбәребез ﷺ әйтә:

- *"Кем намазларны вакытында башкара, шул кешегә ул намаз нур һәм дәлил булыр, һәм ул кеше кыямәт көнендә сакланганнардан булыр"* (Имам Ахмәд 6540-нче хәдис, Ад-Дарими 2721-нче хәдис)
- *"Мөселманлык белән көферлекнең һәм ширекнөң арасы намаз калдыру"* (Муслим 82-нче хәдис)
- *"Намазларыгызны, ничек минем укуымны курдегез, шулай итеп укыгыз"* (Ал-Бухари 631-нче хәдис)

# ПӘЙГАМБӘРӘБЕЗНЕН ﷺ НАМАЗ УКУ ТӘРТИБЕ




صفة صلاة النبي ﷺ -باختصار-

باللغة التترية

بلغات العالم *50 لغة*
غازي بن علي سلطان الداغستاني
المتخرج من الجامعة الإسلامية بالمدينة المنورة
المدينة المنورة +966504352709
1432/2011 +201115587559

(1) Алла'һы Тәгалә ризалыгы өчен намаз укырга теләсәң, синең өстендә тора: тулы тәһарәтле булу, тәнең, киемең, намаз укый торган урыныӊ һәртөрле нәҗесләрдән пакъ булуы, кыйбла тарафына юнәлеп басу, һәм теләгән намазыңны күңелең белән ниятләү.

(2) Беренче сүрәттә күрсәтелгән кебек, сәҗдә кыла торган урынга карап, кулларыңны колаклар турысына күтәрәп, әйт ихрам тәкбирен:




"اَللَّهُ أَكْبَرُ" "Алла'һу әкбәр"

*"Аллаһ бөек"*

(3) Шуннан соң уң кулыңны сул кулың өстенә куй һәм истифтәх догасын укы:

"سُبْحَانَكَ اللَّهُمَّ وَبِحَمْدِكَ، وَتَبَارَكَ اسْمُكَ، وَتَعَالَى جَدُّكَ، وَلاَ إِلَهَ غَيْرُكَ"

**"Субхә'нәкә-Лла'һүммә вә бихәмдикә вә тәбә'ракә-смүкә вә тәа'лә' җәддүкә вә лә' илә'һә гайрук"**

***"Ий Алла'һ, Сине барлык кимчелектән пакълыйм, Сине барлык мактаулар белән мактыйм, Синең исемең Мөбәрәктер һәм дәрәҗәң Олугдыр. Синнән башка һичбер хак, дөрес илаһ юк тыр".***

Шуннан соң әйт:

"أَعُوذُ بِاللهِ مِنَ الشَّيْطَانِ الرَّجِيمِ"

**"Әу'зү би-Лләһи минәшшәйта'нир-ражи'м"**

***"Алла'һка сыгынам шайтанның явызлыгыннан"***

-дип Фатиха сүрәсен укы:

﴿بِسْمِ اللهِ الرَّحْمَنِ الرَّحِيمِ(١) اَلْحَمْدُ لِلَّهِ رَبِّ الْعَـــالَمِينَ(٢) اَلرَّحْمَنِ الرَّحِيمِ(٣) مَالِكِ يَوْمِ الدِّينِ(٤) إِيَّاكَ نَعْبُـــدُ وَإِيَّـــاكَ نَسْتَعِينُ(٥) اهْدِنَا الصِّرَاطَ الْمُسْتَقِيمَ(٦) صِرَاطَ الَّذِينَ أَنْعَمْتَ عَلَيْهِمْ غَيْرِ الْمَغْضُوبِ عَلَيْهِمْ وَلاَ الضَّآلِّينَ(٧)﴾ "آمِينْ"

**﴿Бисми-Лләһи-Ррахмә'ни-Ррахи'м. Әлхәмду ли-Лләһи раббиль-á'ләми'н. Ә-Ррахмә'ни-Ррахи'м. Мә'лики йәуми-**



**дди'н. Иййә'кә нәáбүдү уә иййә'кә нәстәыи'н. Иһдинә-ссыра'таль-мустәкыи'м. Сыра'та-лләзи'нә әнáмтә áләйһим, гайриль-мәгъду'би áләйһим вәләдда'лли'н﴾ "Ә'ми'н!"**


**﴿Рәхимле, шәфкатьле Алла'һ исеме белән башлыйм. Чын мактау галәмнәрне, бөтен мәхлукларны тәрбияләүче Алла'һы Тәгаләгә тиешле. Алла'һы Тәгалә бу дөньяда барча кешеләргә мәрхәмәтле, ягьни мөэминнәргә дә, кәферләргә дә нигьмәтләрен бирә, әмма ахирәттә мөэмин бәндәләренә генә бирәчәк. Алла'һы Тәгалә, -гаделлек белән хөкем итүче, ахирәт көненең патшасыдыр. Ий, тәрбиячебез Алла'һ! Без Сиңа гына гыйбадәт кылабыз һәм һәр эшебездә Синнән генә ярдәм сорыйбыз. Ий, тәрбиячебез Алла'һ! Безләрне туры юлга күндер! (туры юл-Корьән һәм сөннәт юлыдыр). Ул юлны Син әүвәлгеләргә рәхмәт итеп бирдең, безләрне Синең ачуың төшкән вә адашкан кешеләрнең юлыннан, башка юлга күндер, ягьни Сине ачуландырмаган һәм хак юлдан адашмаган кешеләр юлына күндер!﴾**

***"Әмин"***

Һәм белгән сүрәңне кушып дәвам ит.

(4) Рөкугъка кит әйтеп:

"اَللَّهُ أَكْبَرُ" "Алла'һу әкбәр"




Рөкугъта булганда,башың аркаң белән тигез торсын. Тезләреңә кулларыңны бармак аралары аерылган рәвештә куй (2-нче сүрәттәге кебек), рөкугъ кылганда өч мәртәбә әйт:

"سُبْحَانَ رَبِّيَ الْعَظِيمِ" **"Субхәәнә раббийәл азыйиим"**

***"Олуг Раббымны барлык кимчелектән пакълыйм".***

(5) Рөкугътан күтәрелгәндә әйт:

"سَمِعَ اللَّهُ لِمَنْ حَمِدَهُ"

**"Сәмиá-Лла'һу лимән хәмидәh"**

***"Алла'һы Тәгалә Үзен мактаган кешенең, мактавын ишетә һәм аңа җавап бирә"***

Турайгач, әйт:

"رَبَّنَا وَلَكَ الْحَمْدُ، حَمْدًا كَثِيرًا طَيِّبًا مُبَارَكًا فِيهِ"



**"Раббәнә' вә ләкәль-хәмду, хәмдән кәсиран тайибән мубә'ракән фиһ"**


***"Ий, Раббыбыз, барча мактау Сиңа гынадыр, Сине күп, яхшы, мөбәрәк мактау белән мактыйм".***

(6) Соңыннан сәҗдәгә кит әйтеп:

"اَللَّهُ أَكْبَرُ" **"Алла'һу әкбәр"**




(Җиргә төшкәндә иң алда тезләреңне, аннары кулларыңны куй (3,1-3,4 нче сүрәтләрдә күрсәтелгәнчә). Кул һәм аяк бармакларыңны кыйбла тарафына карат, кулларыңны колак турысына куй. Шул вакытта корсак тезләргә тереләми. Терсәкләр җиргә тими. Сәҗдә түбәндәге әгъзалар белән кылынырга тиеш: маңгай белән борын, ике кул очы, ике тез башы, ике аяк бармаклары (4,1-4,4 нче сүрәтләрдә күрсәтелгән).




Сәҗдә вакытында өч мәртәбә әйт:

"سُبْحَانَ رَبِّيَ الْأَعْلَى"

**“Субхә'нә Раббийәль-әгълә'”**

***"Иң югары һәм югарыда булучы Раббымны барлык кимчелектән пакълыйм"***



Сәҗдәдә булганда, Алла'һы Тәгаләдән теләгәнеңне сорасаң була (гарәпчә белмәсәң, ана телеңдә була).

(7) Сәҗдә кылганнан соң башыңны күтәр әйтәп: "اَللَّهُ أَكْبَرُ" **"Алла'һу әкбәр"**

Шуннан соң түбәндәге рәвештә утыр (уң аягыңны бастырып куеп, сул аягыңны җәеп өстенә утыр, кулларыңны тезләреңә куй 5-нчы сүрәт). Утыргач, ике тапкыр әйт:




"رَبِّ اغْفِرْ لِي"

**"Раббигфирь ли"**

***"Ий, Раббым, мине ярлыка".***

(8) Икенче сәҗдәгә бар (4,1-4,4 нче сүрәт) әйтеп:

"اَللَّهُ أَكْبَرُ" **"Алла'һу әкбәр"**

Сәҗдә кылганда, яңадан өч мәртәбә әйт:

"سُبْحَانَ رَبِّيَ الْأَعْلَى"


**“Субхә'нә Раббийәль-әгълә'”**

(9) Кулларың белән тезләреңә таянып, сәҗдәдән икенче рәкагәткә торганда (киресенчә 3-нче сүрәт) әйт:

"اَللَّهُ أَكْبَرُ" **"Алла'һу әкбәр"**

(10) Фатиха сүрәсен һәм берәр белгән сүрәңне аңа кушып укы (уң кулыңны сул кулың өстенә куй). Икенче рәкагәтне беренче рәкагәт кебек укы.

(11) Әгәр дә иртәнге һәм җомга намазы кебек ике рәкагәтле намаз булса, икенче рәкагәтнең икенче сәҗдәсеннән соң утырып кал (6-нче сүрәттәге кебек)









һәм тәшәһһүд догасын укы:

"اَلتَّحِيَّاتُ لِلَّهِ، وَالصَّلَوَاتُ وَالطَّيِّبَاتُ، اَلسَّلاَمُ عَلَيْكَ أَيُّهَا النَّبِيُّ وَرَحْمَةُ اللهِ وَبَرَكَاتُهُ، اَلسَّلاَمُ عَلَيْنَا وَعَلَى عِبَادِ اللهِ الصَّالِحِينَ. أَشْهَدُ أَن لاَّ إِلَهَ إِلاَّ اللهُ، وَأَشْهَدُ أَنَّ مُحَمَّدًا عَبْدُهُ وَرَسُولُهُ"

**"Әттәхийә'тү ли-Лләһи вә-ссаләвә'тү вә-ттайййибә'т, әссәлә'му áләйкә әййүһә-ннәбиййү вә рахмәтү-Лла'һи вә бәракә'түh. Әссәлә'мү áләйнә' вә áлә' ыйбә'ди-Лләһи-сса'лихи'н. Әшһәдү әллә' илә'һә иллә-Лла'һу вә әшһәдү әннә Мухәммәдән áбдуһү вә расү'лүh"**

***"Барча сәламнәр, бөекләү һәм тел гыйбадәтләре, тән гыйбадәтләре , мал гыйбадәтләре , һәркайсы Алла'һы Тәгалә өчендер. Ий, Пәйгамбәребез, сиңа Алла'һы Тәгаләнең сәламе, рәхмәте һәм бәракәтләре булсын. Шулай ук сәлам безгә һәм Алла'һы Тәгаләнең һәрбер изге бәндәләренә дә булсын. Шәһәдәт бирәмен ки, тәхкыйк, Алла'һы Тәгаләдән башка һичбер хак, дөрес илаһ юк һәм Мөхәммәд галәйһиссәләм Алла'һы Тәгаләнең колы һәм илчесе"***

Шуннан соң Салават догасын укы:

"اَللَّهُمَّ صَلِّ عَلَى مُحَمَّدٍ وَعَلَى آلِ مُحَمَّدٍ، كَمَا صَلَّيْتَ عَلَى إِبْرَاهِيمَ وَعَلَى آلِ إِبْرَاهِيمَ، إِنَّكَ حَمِيدٌ مَجِيدٌ. اَللَّهُمَّ بَـــارِكْ عَلَى مُحَمَّدٍ وَعَلَى آلِ مُحَمَّدٍ كَمَا بَارَكْتَ عَلَى إِبْرَاهِيمَ وَعَلَى آلِ إِبْرَاهِيمَ، إِنَّكَ حَمِيدٌ مَجِيدٌ"

**"Алла'һүммә салли áлә' Мухәммәдин вә áлә' ә'ли Мухәммәд, кәмә' салләйтә áлә' Ибра'һи'мә вә áлә' ә'ли Ибра'һи'мә иннәкә Хәми'ду-Ммәҗи'д. Алла'һүммә бә'рик áлә' Мухәммәдин вә áлә' ә'ли Мухәммәд, кәмә' бә'рактә áлә' Ибра'һи'мә**